РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл жирлеге
Советы

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьлэр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru, сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июленнән № 14

Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының
2006 елның 5 январендәге 2 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл
җирлеге Советы депутаты статусы турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфа изаты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының « Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2006 елның 5 январендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасында «, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 11 статьясын түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«Депутат үзэшчәнлеге мәсьәләләре буенчаТүбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул итү хокукыннан файдалана.»;

1.3. Нигезләмәнең 12 статьясында «, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм аларның вазыйфаи затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 1 пунктында «оештыру хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктында «муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм аларның вазыйфаи затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 4 пунктында «оештыру хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 5 пунктында «, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. Нигезләмәнең 14 статьясындагы 1 пунктында «, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. Нигезләмәнең 17 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«шәхсән яки ышанычлы вәкилләр аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерцияле оешма белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы, башка муниципаль берәмлекләр берләшмәләре, сәяси партия, профсоюз идарәсендә катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлеше) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә кую тәртибен билгели торган муниципаль хокукыйактлар нигезендә, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлекмән фәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда;

1.10. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 2 пунктында «, аларның оештыру-хокукый формаларыннан һәм җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган тиешле территория чикләрендә урнашкан милек формаларына бәйсез рәвештә, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай уканы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җирлекнең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов